МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.11.2023 Казан шәһәре № 221-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарын үтәү йөзеннән

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр
урынбасары – министр О.В.Коробченко

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2023
елның «20» 11.2023
221-ОД номерлы боерыгы
белән расланды

## Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре администраторы буларак Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләргә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы бюджетына (алга таба – бюджет) түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен билгели.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы нигезендә бюджетка түләүләр буенча бурыч (билгеләнгән срокта түләнмәгән бюджетка түләүләр) түбәндәге очракларда түләтүгә өметсез дип таныла:

1) физик зат – бюджетка түләүләр түләүче зат вафат булганда яисә Россия Федерациясенең граждани-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгәндә;

2) шәхси эшкуар – бюджетка түләүләр түләүче затның мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле түләнмәгән бурычы өлешендә «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип танылганда;

3) шәхси эшкуар булмаган гражданинны «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип тану – әлеге Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә;

4) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә оешма – бюджетка түләүләр түләүче

зат бетерелгән очракта;

5) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы буларак Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә;

6) суд приставы-башкаручысы тарафыннан «Үтәтү эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлегенең тәмамлануы һәм түләттерүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан башлап биш елдан күбрәк вакыт узса, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме бурычлы затка карата банкротлык турында эш кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

бюджетка түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эш туктатылганда;

7) теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, «Үтәтү эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча әҗәт өлешендә. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча әҗәт бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш;

8) әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган,

вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса (түләнмәгән административ штрафларга карата);

3. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар (алга таба – карар) Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финанс активларын һәм йөкләмәләрен инвентаризацияләү нәтиҗәләрен карау буенча даими эшләүче комиссия (алга таба – Комиссия) тарафыннан түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча исәпкә алына торган бурыч турында, бюджет керемнәре администраторы буларак, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы хисапларыннан өземтәләр (бюджетка түләүләр буенча исәпкә алына торган бурыч турында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы бюджет исәбен алып бару мәгълүматларыннан белешмәләр);

б) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында белешмәләр;

в) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлемен раслаучы яки аны үлгән дип игълан итү фактын раслаучы документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

шәхси эшкуариндивидуаль эшкуар булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче граждан милкен, шулай ук шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан физик зат – түләүче тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына шәхси эшкуар буларак түләүләрне туктату турында белешмәләрне үз эченә алган документны гамәлгә ашыруны тәмамлау турында суд акты (банкрот) (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән очракта) конкурс производствосын тәмамлау яисә мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешманы бетерү белән бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлар булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 4

пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы буларак Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган штраф яки суд акты рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки кичерү турында акт (түләнмәгән административ штрафларга карата) (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

«Үтәтү эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән очракта) җәзага тартылучыга башкарма документ кайтарылу белән бәйле рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы – башкаручысы карары;

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 6 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 8 пунктчасында күрсәтелгән очракта).

4. Комиссия эшен оештыру ягыннан Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финансларны планлаштыру, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге тәэмин итә.

5. Комиссиядә бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен карау өчен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының структур бүлекчәсе – керемнәр администраторы Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финансларны планлаштыру, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлегенә аның буенча бурыч барлыкка килгән һәм түләтүгә ышанычсыз дип танылырга тәкъдим ителә торган бюджет кеременә түләү турында белешмәләр булган хезмәт хатын җибәрә. Хезмәт хатына әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлә.

6. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финансларны планлаштыру, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге документларны аларның

тулылыгы һәм комплектлылыгы буенча карый һәм Комиссиягә җибәрә.

7. Комиссияне Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Рәис булмаганда, аның вазыйфаларын рәис урынбасары башкара.

8. Комиссиянең 5 кешедән торган шәхси составы (рәис, рәис урынбасары һәм Комиссия әгъзалары) Министрлык боерыгы белән раслана.

9. Комиссия кирәк булуга карап утырышлар үткәрә.

10. Комиссия карарлары, әгәр аның утырышында Комиссиянең барлык әгъзалары катнашса, хокуклы дип санала.

11. Комиссия Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финансларны планлаштыру, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге тәкъдим иткән документларны Комиссиягә кергән көннән алып унбиш эш көне дәвамында карый. Комиссия утырышы уздырылганнан соң унбиш эш көне эчендә карар проекты әзерләнә һәм акт рәсмиләштерелә.

12. Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссиянең барлык әгъзалары кул куя.

13. Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документлар булганда түләтүгә өметсез дип танырга;

2) әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документлар булмаганда, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танудан баш тартырга. Әлеге карар Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен кабат карауга комачауламый.

Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

Комиссиянең бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карары Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзаланган һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

а) оешманың тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

б) салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик затның салым түләүчесенең идентификацияләү номеры) (булган очракта);

в) бурычны барлыкка китергән түләү турында белешмәләр;

г) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны исәпкә алган бюджет керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

д) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн;

з) Комиссия әгъзаларының имзалары.

14. Комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы акт Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министры тарафыннан раслана.

15. Бюджетка түләүләр буенча бурычны бюджет исәбеннән исәптән чыгару Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финансларны планлаштыру, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы боерыгы нигезендә башкарыла.